






# Туган ягым- Татарстан







# Туган илебез- Россия Федерациясе







**Конституция – илебезнең Төп Законы.**


**Закон – ул үтәлүе мәҗбүри булган кагыйдәләр җыелмасы.**

## РФ Конституциясе ничек барлыкка килгән соң?

Башта Конституцияне галимнәр язганнар. Аннан соң Россия гражданнары аны укыганнар, газета һәм телевидение аша фикер алышканнар. Кайбер кагыйдәләрне Конституциядән сызганнар, өстәгәннәр, үзгәрткәннәр.

Шулай итеп, 1993 нче елның 12 декабрендә аны кабул иткәннәр. Һәм бу көн Халыкара бәйрәмгә әйләнгән. Быел 12 декабрьдә РФ Конституциясе кабул ителүгә 24 ел булды.

**Гражданин - Россиядә туган һәм анда даими торучы кеше.**




***12 декабрь -***
***Россия Федерациясе***
***Конституциясе көне.***




*1918 ел*




*1924 ел*




*1936 ел*




*1977 ел*

# Конституцияләр тарихыннан

## РФ Конституциясендә нәрсә әйтелгән соң?

РФ Конституциясендә Россия гражданнарының хокуклары һәм бурычлары чагылган.



Бала туганда ук аның хокуклары була.

-бала тормышка,ата-ана кайгыртуына;

- белем алырга;

- ял итәргә;

- медицина ярдәме алуга,









## Кешенең хокукларыннан тыш , бурычлары да бар.

-Башка кешеләрнең хокукларын хөрмәт итәргә;

-Ватанны сакларга;


-Салым түләргә;

-Балаларны тәрбияләргә;

-Табигатьне, тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне сакларга тиешбез.







Безнең дәүләтебез белән кем идарә итә?



**Владимир Владимирович Путин**

# Россиянең башкаласы - Мәскәү





# Россиянең символикасы.

## Герб, флаг, гимн

Символлар–шартлы билгеләр һәм сурәтләр. Дәүләт символлары дәүләтнең һәм аның халкының тарихын чагылдыралар.



Герб - һәр дәүләтнең төп символы, аның эмблемасы. Ул байракларда, печатьләрдә, акча-ларда, документларның (паспорт) бланкларында сурәтләнә.



Дәүләт флагы- һәр дәүләтнең аерымлык билгесе, аның азатлыгы, бәйсезлеге һәм мөстәкыйльлеге символы.

# Гимн.

Дәүләт хөрмәтенә язылган тантаналы музыкаль әсәрне гимн дип атыйлар. «Гимн » сүзе грекча «тантаналы мактау җыры» дигәнне аңлата. Аның музыкасы һәрвакыт тантаналы, күтәренке рухлы, хисчән яңгырашлы. Дәүләт гимнының авторлары- композитор Александр Александров һәм шагыйрь Сергей Михалков.











* Татарстан Республикасының символлары.

# Сораулар

- Безнең илебез ничек атала?
- Кайсы шәһәр Россиянең башкаласы булып тора?
- Дәүләт белән кем идарә итә?
- Россия президентын атагыз.
- РФ символларын ата.
- Россия Дәүләт гербында нәрсә сурәтләнелгән?

-Россиянең Дәүләт флагының төсләрен атагыз.

-Син яшәгән Республиканың исеме ничек?

-Сезнең республика башкаласы нинди шәһәр?

-Татарстан президентын әйтегез.

- Татарстан Республикасының Дәүләт флагының төсләрен атагыз.

- Тантаналар вакытында гимны ничек тыңлыйлар?

Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

## Кулланылган әдәбият:

1.Конституция и государственная символика Российской Федерации. «ЭКСМО» Москва 2012

2. «Дөньяви этика нигезләре» 4,5 сыйныфлар өчен дәреслек. М.Т.Студеникин,Казан “Хәтер” нәшрияте, 2012

3.Интернет- ресурслар: fotostrana.ru, images.yandex.ru› geraldika.ru›Символика России

электронная почта: j-fira@mail.ru, n.ura@bk.ru